МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

24.03.2020 г.Казань № 192

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2020 елның 16 апрелендә 6616 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү өчен субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 634 номерлы боерыгы белән расланган Торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү өчен субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында һәм Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының аерым боерыкларының һәм нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында

Дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү өчен субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 634 номерлы боерыгы белән расланган Торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү өчен субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына

кертелә торган кушымтадагы үзгәрешләрне расларга (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 09.07.2015 ел № 461, 09.11.2015 ел № 821, 07.06.2016 ел № 317, 20.07.2016 ел № 420, 28.11.2016 ел № 668, 27.02.2017 ел № 104, 08.06.2017 ел № 349, 28.05.2018 ел № 401, 18.09.2018 ел № 857, 04.02.2019 ел № 77, 07.05.2019 ел № 322, 10.09.2019 ел № 689, 14.11.2019 ел № 1021 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән).

2. Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының "Тәрбиягә алынганнарын да кертеп, 18 яшькә кадәрге яшьтәге өч һәм аннан артыграк баласы булган гаиләләргә торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү өчен субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында" 2014 елның 01 декабрендәге 670 номерлы боерыгын;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2016 елның 19 маендагы 277 номерлы «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2014 елның 01 декабрендәге 670 номерлы боерыгы белән расланган Тәрбиягә алынганнарын да кертеп, 18 яшькә кадәрге яшьтәге өч һәм аннан артыграк баласы булган гаиләләргә торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү өчен субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында» боерыгын;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2016 елның 28 ноябрендәге 668 номерлы «Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында» боерыгы белән расланган дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган 7 пунктны;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2017 елның 27 февралендәге 103 номерлы «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2014 елның 01 декабрендәге 670 номерлы боерыгы белән расланган Тәрбиягә алынганнарын да кертеп, 18 яшькә кадәрге яшьтәге өч һәм аннан артыграк баласы булган гаиләләргә торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү өчен субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында» боерыгын;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2017 елның 08 июнендәге 349 номерлы «Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү хакында» боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган 1 пунктның икенче абзацын;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2018 елның 14 сентябрендәге 855 номерлы «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2014 елның 01 декабрендәге 670 номерлы боерыгы белән расланган

«Тәрбиягә алынганнарын да кертеп, 18 яшькә кадәрге яшьтәге өч һәм аннан артыграк баласы булган гаиләләргә торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү өчен субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» боерыгы белән расланган Тәрбиягә алынганнарын да кертеп, 18 яшькә кадәрге яшьтәге өч һәм аннан артыграк баласы булган гаиләләргә торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү өчен субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакындагы» боерыгын;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2019 елның 22 апрелендәге 290 номерлы «Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында» боерыгы белән расланган халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләрнең 4 пунктына;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2019 елның 19 августындагы 635 номерлы «Халыкка социаль ярдәм өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында» боерыгы белән расланган халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләрнең 2 пунктына;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2019 елның 07 ноябрендәге 933 номерлы «Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында» боерыгы белән расланган халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләрнең 3 пунктына;

Министр вазыйфасын башкаручы Р.Ф. Валиуллов

Расланды
Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2020 елның 03 мартындагы 192 номерлы боерыгы белән

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2014 елның 19 ноябрендәге 634 номерлы «Торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү өчен субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» боерыгы белән расланган Торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү өчен субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр

1 бүлекнең 1.2 пунктында:

1.2 пунктның өченче абзацында «җинаять-үтәтү системасы» сүзләреннән соң «Россия Федерациясе мәҗбүри башкару органнары,» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) 1995 елның 12 гыйнварындагы «Ветераннар хакында» 5-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 1 пунктының «а»-«ж», «и» пунктчаларында күрсәтелгән затлар арасыннан Бөек Ватан сугышында катнашучылар;»;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) 1995 елның 12 гыйнварындагы «Ветераннар хакында» 5-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 пунктның 1 - 4 пунктчаларында күрсәтелгән затлар арасыннан хәрби хәрәкәтләр ветераннары;»;

җиденче – унберенче абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацны өстәргә:

«41) тәрбиягә алган балаларны да кертеп, 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан күбрәк баласы булган гаилә әгъзалары.»;

2 бүлектә:

2.4 пунктының «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасында дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидия-ташлама билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар мөрәҗәгать итүчегә субсидия-ташлама билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көннән башлап, бер эш көне эчендә гаризада күрсәтелгән ысул белән хәбәр ителә.»;

2.5 пунктының "Стандартка таләпләр эчтәлеге" графасында:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Социаль түләүләрне алу өчен банкта яки башка кредит учреждениесендә федераль законнар нигезендә ачылган счетның реквизитлары күрсәтелгән субсидия-ташлама бирү турында гариза. Гаризаның киңәш ителә торган формасы әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән.»;

дүртенче – җиденче абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга (әлеге абзац таләбе 2021 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә);

2.6 пунктта:

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасында:

унынчы абзацта «инвалид балалары булган гаиләләргә» сүзләрен «әлеге Регламентның 1.2 пунктының 12 һәм 41 пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләргә» сүзләренә алмаштырырга;

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү, баланы җирле үзидарә органнарындагы гаиләгә тапшыру турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктындагы 12 һәм 41 пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләргә субсидияләр-ташламалар билгеләү өчен) (җирле үзидарә органнарында);»;

уникенче абзацта «инвалид балалары булган гаиләләргә» сүзләрен «әлеге Регламентның 1.2 пунктының 12 һәм 41 пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләргә» сүзләренә алмаштырырга;

унөченче абзацта «инвалид балалары булган гаиләләргә» сүзләрен «әлеге Регламентның 1.2 пунктының 12 һәм 41 пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләргә» сүзләренә алмаштырырга;

«Хезмәтне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында «2.1» санын «2.2.1» санына алмаштырырга;

2.16 пунктындагы «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гариза һәм документларның электрон документлар рәвешендә күчермәләре Үзәк бүлегенә гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән Интернет челтәре ярдәмендә җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан Үзәк бүлегенә электрон йөрткечләрдә тапшырылырга мөмкин. Шул ук вакытта гариза гади электрон имза белән имзаланырга тиеш, ә гаризага теркәлә торган документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы Федераль законның $21^1$ һәм $21^2$ статьялары таләпләре нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә электрон имза белән таныкланырга тиеш.

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яисә Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша гаризаны түбәндәге категориядәге затлар җибәрергә мөмкин:

Россия Федерациясе Пенсия Фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге аша айлык акчалата түләү алучы инвалидлар;

граждан хәле актларын теркәү (инвалид бала туу, никахлашу, аерылышу) Татарстан Республикасында башкарылган һәм инвалид бала белән бергә яшәгән очракта, Россия Федерациясе Пенсия Фонды бүлеге аша инвалид балаларның айлык акчалата түләү алучы ата-аналары;

инвалид баланың туауын теркәү Татарстан Республикасында башкарылган очракта, Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге аша ай саен акчалата түләү алучы инвалид балаларның опекуннары;

тәрбиягә алынганнарын да кертеп, 18 яшькә кадәрге яшьтәге өч һәм аннан артыграк баласы булган ата-аналар, гаиләсендә тууын Татарстан Республикасыннан

читтә теркәгән балалар булган ата-аналардан тыш, яисә Татарстан Республикасыннан читтә урнашкан мәгариф оешмаларында яисә урта һөнәри белем бирү оешмаларында яисә югары уку йортларында белем алучы балалар булган гаиләләрдән тыш; балаларының атасы (анасы) белән никахта тормаган ата-аналардан һәм тол яки ялгыз ана булмаганнардан тыш; балалары белән төрле адреслар буенча теркәлгән ата-аналардан тыш.

Гаризаны Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яисә Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматы аша биргәндә дәүләт хезмәте нәтиҗәсе электрон рәвештә күрсәтелә.»

3 бүлекнең 3.4.2 пунктындагы өченче абзацында «Россия Федерациясе Пенсия фондында» сүзләрен «вәкаләтле органда» сүзләренә алмаштырырга.